СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07.07.2021г. п.г.т. Аксубаево № 56

Аксубай муниципаль район Советының 2019 ел,13 декабрь, 230 нчы карары белән расланган «Муниципаль вазыйфага яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнарның, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында» 2020 ел, 10 декабрь, 778 нче Указын үтәү йөзеннән Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1Аксубай муниципаль районы Советының 2019 ел,13 декабрь, 230 нчы карары белән расланган «Муниципаль вазыйфага яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнарның, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3. пунктның «3» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләре, акцияләре (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча башкарылган алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда әлеге гражданның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм бу алыш-бирешләр кылган финанс чараларын алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

1.2. 2.4. пунктның «3» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләре (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча башкарылган алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге соңгы өч елда әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм бу алыш-бирешләр кылган финанс чараларын алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе К.К.Гыйлманов